**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**30.12.2021** **№ 47**

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, Зәй муниципаль районы Кадер җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы закон), Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, Зәй муниципаль районы Кадер җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 23 маендагы 126 номерлы, 2018 елның 26 ноябрендәге 150 номерлы, 2018 елның 07 декабрендәге 155 номерлы, 2020 елның 22 сентябрендәге 05 номерлы карарлар нигезендә кертелгән өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарә органнарындагы белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2 бүлеге 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә керә торган муниципаль хезмәт

вазыйфасына билгеләнгәндә, класс чины өчен аның оклад күләме ул биләгән вазыйфа кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин бирелгәнче, вазыйфаи окладка карата процент ставкасыннан чыгып, 3 процентка тигез итеп исәпләнә.

Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының түбәнрәк төркеменә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, һәм моңа кадәр биләгән вазыйфа буенча аңа бирелгән класс чины, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып, 7 процентка тигез итеп исәпләнә.»;

2. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә;

әлеге документның гамәлдә булуы 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**Кадер авыл җирлеге башлыгы** **Р.М. Нурллин**